Раслыйм:
Иләбәр "Умырзая" балалар бакчасы
мөдире ____________ Г.М.Нагимова
"31"август 2024 ел

Татарстан республикасы Саба муниципаль районы "Иләбәр "Умырзая" балалар бакчасы

# 2024-2025 нче уку елына тәрбия эшенең календарь тематик планы

| № | Тема | Вакыты | Максат | Һәр төркем балалары өчен |
|---|---|---|---|---|
| 1. | **Минем бакчам, җәйдән соң очрашу.Безнең төркем.** | 02.–07.09. | Балалар бакчасына карата ярату хисе тәрбияләү, игътибарлылыкларын, куелган максатны аңлый белү сәләте үстерү,дусларына һәрвакыт булышырга, ярдәмгә килергә кирәклеген төшендерү. Тәрбияче, укытучы һәм башка бакча хезмәткәрләре хөнәрләре турында беренче күзаллауны формалаштыру һәм аларга карата хөрмәт тәрбияләү;бакча хезмәткәрләренең эш процессын күзәтү;<br>төркемдәге балалар белән якыннан танышу. | **Патриотик тәрбия**<br>Әңгәмә: «Балалар бакчасында» З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 14 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе**<br>Тәрбияче ярдәмчесенең хезмәтен күзәтү, өстәл әзерләргә булышу.<br>Сүзле уен «Без инде хәзер зурлар» (балалар, сүзләргә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар). З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 16 бит<br>**Социаль тәрбия**<br>Җырлы уен «Күңелле бакчабыз» З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 13 бит<br>**Танып белү тәрбиясе**<br>«Дөресен әйт» уены (туп ярдәмендә).<br>З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 14 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>Дидактик уен. «Дөрес итеп тез» (эчтәлекле рәсемнәр сериясе – «Иртә»; бала йокыдан уяна, урынын җыя, гимнастика ясый, юына, ашый, киенә, әнисе белән балалар бакчасына бара, тәрбияче каршы ала)<br>З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 15бит<br>**Этик-эстетик тәрбия**<br>Фото күргәзмә: "Жэйнен матур тослэре" |
| 2. | **Ел фасыллары. "Исәнме, Алтын көз!" Көзге үзгәрешләр. (табигать, кеше киемнәре)** | 09.-14.09 | Көзнең характерлы үзенчәлекләре, табигатьтәге үзгәрешләр, кешеләрнең эшчәнлеге;<br>ел фасыллары, ай исемнәре турында белемнәрен ныгыту;<br>тере булмаган табигатьтә күзаллауларны киңәйтү;<br>Балаларның иҗади кузаллауларын, кузәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен үстерү. | **Патриотик тәрбия** хикәя төзү."Алтын көз<br>З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 24 бит УМК<br>**Хезмәт тәрбиясе** Яфраклар җыю<br>**Социаль тәрбия**<br>Җырлы уен «Көз һәм яңгыр». З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 24 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Бакча тирәли экскурсия (көзне чагылдырган барлык үзгәрешләрне күзәтү). З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 24 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия**<br>"Козге алмагач" темасына рәсем конкурсы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3. | **Көз күчтәнәчләре** | 16-21.09. | Яшелчәләр, җиләк-җимешләр турында белемнәрне киңәйтү, системалаштыру, алган белемнәрен уеннар барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү;<br>җиләк-җимеш бакчасы, басу-кыр турында мәгълүмат бирү;предметларны классификацияләү күнекмәләрен ныгыту; балаларның иҗади күзаллауларын, күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен үстерү; | **Патриотик тәрбия**<br>Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү. «Мин уңыш җыйдым» З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 159 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе**<br>«Бакчада көзге эшләр» З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 158 бит<br>**Социаль тәрбия**<br>«Тәмле!» уены**.** З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 160 бит<br>**Танып белү тәрбиясе**<br>«Кем зирәк, әйт тизрәк!» уены З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 161 бит.<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>Хәрәкәтле уен «Яшелчә ашы һәм җимеш суы әзерлибез» З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 161 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия**<br>Җиләк –җимеш һәм яшелчә"-гаилә фотографияәлә реннән күргәзмә. |
| 4. | **Йорт һәм кыргый хайваннар, кошлар көз көне.** | 23.09-28.09. | Хайваннар,йорт кошлары аларның үзенчәлекләре (тышкы билгеләре, яшәү рәвешләре) һәм файдалары турында белемнәрен баету, системалаштыру;<br>аларга карата сак караш, миһербанлылык тәрбияләү.аларның кышка ничек әзерләнүләрен белү | **Патриотик тәрбия**<br>"Кош рәсемнәрен җый"Пазл җыю.<br>**Хезмәт тәрбиясе**<br>Өлкәннәрнең хайваннарны ашатуларын күзәтү.<br>**Социаль тәрбия**<br>Тизәйткеч "Мич башында биш мәче"<br>**Танып белү тәрбиясе**<br>Дидактик уен «Нәрсә ничек кычкыра?» (туп белән).<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>Уен: "Казлар – казлар"<br>**Этик-эстетик тәрбия** Әвәләү юлы белән эшләгән хайваннарга күргәзмә. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | **Тәрбиячеләр көне. Өлкәннәр көне.** | 30.09.-05.10 | Тәрбиячеләргә,өлкәннәргә игътибар,ихтирам тәрбияләү;гаиләдә өлкәннәр тәрбиясенең әһәмиятен аңлату; олыларга булышу шатлык икәненә инандыру; | **Патриотик тәрбия**<br>Әңгәмә үткәрү. “Безнең балалар бакчасында кемнәр эшли?”<br>**Хезмәт тәрбиясе.**<br>Тәрбияче ярдәмчеләренең эшен күзәтү, аларга ярдәм итү.<br>**Социаль тәрбия**<br>Дидактик уен. “Минем яраткан бакчам”<br>**Танып белү тәрбиясе**<br>“Тәрбиячеләр көне”нә концерт әзерләү, күрсәтү.<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>Әңгәмә үткәрү. “Өлкәннәргә булышыйк!”<br>**Этик-эстетик тәрбия.**<br>“Өлкәннәр көне”нә открытка ясау. Фотокүргәзмә “Минем яраткан әбием” |
| 6. | **Россия – зур дәүләт. Халыклар бердәмлеге.** | 07.10-12.10 | Балаларның Россия башкаласы Мәскәү, рус милләте турындагы белемнәрен баету, Россия символика-сы турында мәгълүмат бирү; балаларда туган илне ярату, аның белән кызыксыну, туган илгә тугрылык сыйфатлары, башка милләт вәкилләренә карата хөрмәт, дуслык хисләре тәрбияләү. | **Патриотик тәрбия**<br>Россия символикасы белән танышу.<br>**Хезмәт тәрбиясе**<br>Уенчыкларны тәртип белән тезү.<br>**Социаль тәрбия**«Туграны җый» (аерым рәсемнәрне бер-берсенә куеп, Татарстан һәм Россия туграсын җыю).<br>**Танып белү тәрбиясе** Үстерешле уеннар: «Дөрес итеп тез!» (төсле тасмалардан<br>Татарстан һәм Россия әләмен тезү)<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>Төрле милләт биюләрен башкару.<br>**Этик-эстетик тәрбия**<br>Орлыклардан Россия флагын тезү һәм буяу. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7. | **Җир шары – безнең уртак йортыбыз. Сабам-минем туган ягым. Иләбәрем-туган авылым**. | 14.10-19.10 | Балаларны төньяк, көньяк илләре һәм анда яшәүче халыклар, хайваннар,үсемлекләре, карта , глобус белән таныштыру. Балаларны үзебезнең туган авылыбыз, районыбыз белән таныштыру; туган җирне ярату хисе тәрбияләү;Саба районы турындагы белемнәрен тирәнәйтү. | **Патриотик тәрбия**<br>Әңгәмә:”Районыбызның күренекле шәхесләре”<br>**Хезмәт тәрбиясе**<br>Территориягә агач утырту.<br>**Социаль тәрбия**<br>Тозлы камырдан чәк- чәк ясау.<br>**Танып белү тәрбиясе**<br>Авылдашыбыз Миннегөл Манихованың шигырьләрен уку.<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>Уен:”Ак калач”<br>**Этик-эстетик тәрбия** Рәсем конкурсы “Минем яраткан авылым” |
| 8. | **Мониторинг. Китап киңәшчең синең.** | 21.10-26.10 | Китап, аның кайдан килүе, китапханәче хезмәте турында балаларның белемнәрен киңәйтү;<br>китапханә белән турыдан-туры таныштыру аша балаларда күзәтүчәнлек, игътибарлылык, эзлекле фикерләү сәләтен үстерү;<br>китапханәче һөнәренең мөһимлеген аңлату;<br>китапханәче хезмәтенә карата ихтирам, китапханәдә үз-үзеңне тота белү сыйфатлары тәрбияләү;<br>китап карау, укуга, белемгә омтылыш тәрбияләү;<br>китапларга карата сак караш, хөрмәт тәрбияләү | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә: “Сез гаилә белән нинди китаплар укыйсыз?”.<br>**Хезмәт тәрбиясе** “Китаплар шифаханәсе”(китап ремонтлау)**“**Китапханәгә экскурсия**”** Китапханәче хезмәтенә карата ихтирам, китапханәдә үз-үзеңне тота белү сыйфатлары тәрбияләү.<br>**Социаль тәрбия** Зиһен уены «Кайда, нәрсә, ничек?» З.М.Зарипова”Туган телдә сөйләшәбез” 260 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Матур әдәбият уку: Х Шабанов “Кадерлә син китапны”.<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** уен.«Тәртип буенча тез». Китап ремонтлау буенча эчтәлекле рәсемнәр бирелә. Балалар шул рәсемнәрне тәртибе буенча тезеп чыгалар һәм сөйләп бирәләр<br>**Этик-эстетик тәрбия**“Әкиятләр иленә сәяхәт” - әкият сәхнәләштерү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9. | **Әдәплелек дәресләре. Табын янында. Киемнәр дә безне бизиләр. Яхшы сүз- җан азыгы.** | 28.10-1.11 | Балаларда якыннарына, әти-әниләренә карата игътибарлылык, үзеңне әдәпле тоту күнекмәләре тәрбияләү;яхшылык, шәфкатьлелек, дуслык турында күзаллау булдыру;<br>матур әдәбият аша балаларның сөйләмендә ягымлы сүзләр куллануларына ирешү;<br>бер-береңә игътибарлылык, ярдәмләшү, дуслык, үзара хөрмәт хисләре тәрбияләү;<br>балаларда киемнәргә карата зәвык, сакчыл караш тәрбияләү. | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә.- "Сүз эчендә энже бар."Шигырь уку.- В.Хәйруллина. "Табын кагыйдәләре"<br>**Хезмәт тәрбиясе**"Курчак күлмәкләрен юу". Чисталык, пөхтәлек турында такмаклар уку.<br>**Социаль тәрбия** Өстәл театры. «Өч кыз». Татар халык әкияте З.М.Зарипова"Туган телдә сөйләшәбез" 19 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** "Өстәл әдәбе" – "Нәсихәт" китабыннан уку<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Хәрәкәтле уен «Капкалы». Түгәрәктә балалар бию көенә биеп йөриләр, ә ике бала кара каршы басып, кулларын югары күтәреп, «капка» ясыйлар. Көй туктагач, алар кулларын төшерәләр. «Капка» эчендә калган бала «тәмле» сүз әйтә.<br>**Этик-эстетик тәрбия** "Туган көн" күңел ачу кичәсе. |
| 10. | **Минем гаиләм, өем, йорт җиһазлары.** | 4.11-9.11 | Балаларда гаилә әгъзаларенә карата хөрмәт, дәү әни, дәү әтиләрне ярату хисе тәрбияләү; җир йөзендә яшәүче халыкларның торак йортлары, аларның яшәү урыннарына бәйле булуы турында аңлату. | **Патриотик тәрбия** Үстерешле диалог"Минем өем" (табышмаклар ярдәмендә). (171 бит)УМК<br>**Хезмәт тәрбиясе** Гөлләргә су сибү, төпләрен йомшарту, уйнаган уенчыкларны юып тәртипләп урнаштыру.<br>**Социаль тәрбия**"Мин тасвирлыйм син әйт" уены.(172 бит)<br>**Танып белү тәрбиясе** Үсеш бирү уеннары. Табышмак әйтү: (Балачак аланы китабында 425 бит)<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Туплы уен «Тиз уйла!» .(172 бит УМК)<br>**Этик-эстетик тәрбия**"Дәү әнигә- кунакка". Күнел ачу кичәсе. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 11. | **Юлларда иминлек кирәк. Транспорт төрләре.** | 11.11-16.11 | Балаларда транспорт йөртүче һөнәр ияләренә карата хөрмәт, ихтирам һәм урамда, траспортта үз-үзләрен дөрес тоту сыйфатлары тәрбияләү; Балаларның иҗади активлыгын, фикерләү сәләтен үстерү. | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә**:“**Авыл урамында нинди кагыйдәләрне үтәргә кирәк?”.<br>**Хезмәт тәрбиясе«**Транспорт төрләре белән танышу» Балаларда транспорт йөртүче һөнәр ияләренә карата хөрмәт, ихтирам һәм урамда, транспортта үз-үзләрен дөрес тоту сыйфатлары тәрбияләү УМК 208 бит.<br>**Социаль** тәрбияДидактик уен «Дөрес җавап бир!» (төрле транспорт чаралары арасыннан билгеле бер транспортны табу) УМК 209 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Уен.<br>«Транспортта үз-үзеңне тоту кагыйдәләре» (рәсем схемалар кулланып) УМК 211 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе.** Хәрәкәтле уен «Төсле машиналар» УМК 211 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия**“Минем яраткан машинам”, “Минем велосипедым” рәсем күргәзмәсе**.** |
| 12 | **Йорт хайваннары һәм кошлары кыш коне** | 18.11-23.11 | Хайваннар,йорт кошларын танырга , исемнәрен әйтергә өйрәтү ,аларның тышкы билгеләре, яшәү рәвешләре һәм файдалары турында белемнәрен баету, системалаштыру;<br>аларга карата сак караш, миһербанлылык хисе тәрбияләү. | **Патриотик тәрбия**<br>Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү: «Ишегалдында» УМК 71 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе** «Сыер савучы» хезмәтен күзәтү.<br>**Социаль тәрбия** Дидактик уен «Баласын әйт!» Мәсәлән: сыер – бозау, ат – колын, тавык – чеби һ.б УМК 72 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Табышмаклар. УМК 72 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Хәркәтле уен «Песи һәм тычканнар». УМК 73 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия** Кулларыннан гөлләр тама” – әвәләү юлы белән эшләгән эшләргә күргәзмә. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13. | **Әниләр көне. Мин олыларга ярдәмче.** | 25.11-30.11 | Әниләргә хөрмәт, горурлык хисе , балаларда уңганлык, тырышлык, өлгерлек тәрбияләү; киңәшләрне тыңлый белергә, олыларга ярдәм итәргә өйрәтү. | **Патриотик тәрбия .** Әңгәмә. «Олыларны хөрмәтлик!» УМК 35 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе**” Кем матур итеп тәлинкә тезә”<br>**Социаль тәрбия**«Дәү әнигә эндәшү» УМК 36 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Шигырь уку: Ә.Бикчәнтәева. «Дәү әнием». УМК 36 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Хәрәкәтле уен :«Бабай һәм оныклар» УМК 35 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия** “Әнием-күз нурым**”** күнел ачу кичәсе**.** |
| 14. | **Ак ефәктән кыш килде** | 02.12-7.12 | Кыш, кар үзенчәлекләре ,табигатьтә ел фасыллары буенча барган үзгәрешләр турындагы белемнәрен системалаштыру;<br>җәнлекләрнең, кошларның кышка ничек җайлашуы турындагы белемнәрне арттыру;<br>кышкы табигать күренешләренә соклану хисе һәм мәхәббәт уяту;<br>табигатькә сак караш, экологик бәйләнешләрне күрә белү сыйфаты тәрбияләү. | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә. «Кыш килде» УМК 56 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе.** Кечкенә көрәкләр белән сукмактагы карны көрәү.<br>**Социаль тәрбия.** «Сорау – җавап» уены УМК 187 **бит**<br>**Танып белү тәрбиясе** . Рәсем буенча хикәя төзү: «Кышкы уеннар» УМК 58 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе .** Хәрәкәтле уен «Чаналарга!УМК 188 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия. “** Кышкы әкият”- уен тамаша |
| 15. | **Кыргый хайваннар һәм кошлар тормышы.** | 09.12-14.12 | Балаларны хайваннар дөньясы белән таныштыру. Аларда хайваннарга карата кызыксыну һәм сакчыл караш тәрбияләү, мөстәкыйль ,эвристик (уйлап табу) фикерләү сәләтен үстерү.Тышкы билгеләренә карап, тавышын ишетеп хайваннарны аера белергә өйрәтү. | **Патриотик тәрбия** «Зоопаркка сәяхәт» УМК 66 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе** Дидактик уен: “Кыргый хайваннарны ашат”<br>**Социаль тәрбия** Дидактик уен «Дөрес тап! Дөрес итеп билгелә» (интерактив тактада яки рәсемнәрдә кыргый хайваннарның яшәү урыннарын, ризыкларын, табигатькә ничек җайлашуларын ук ярдәмендә билгеләү) УМК 67 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Тасвирлау табышмаклары төзү (кыргый хайваннар турында) Умк 71 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Хәрәкәтле уен. «Куяннар һәм бүре»УМК 67 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия** Табышмаклар кичәсе “Зирәкләр иң кирәкләр... |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 16. | **Кышкы могҗизалар. Яңа ел бәйрәме бүләкләре, символлары. Туган якта һәм башка илләрдә Яңа ел каршылау гореф-гадәтләре.** | 16.12-21.12 | Яңа ел бәйрәме, аңа бездә һәм башка илләрдә ничек әзерләнүләре, нинди әкият геройлары килүе, Кыш ба- бай, Кар кызы турында күзаллауларны киңәйтү;<br>Яңа елның уенчыклары, бүләкләре, могъҗизалары белән таныштыру. | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә:«Килеп җитте матур кыш» УМК 186 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе** Җимлеккә кошлар өчен азык салу<br>**Социаль тәрбия** Дидактик уен «Парын тап» (бирелгән сүзләрне мәгънәләре буенча туры килерлек итеп парлаштыру). Мәсәлән: чаңгы – таяк, чана – тау, кыш – карһ.б. УМК 193 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Табышмаклар<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Сүзле-хәрәкәтле уен «Кышкы паркта» УМК189 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия —**Яңа ел уенчыкла-рыннан күргәзмә |
| 17. | **Балаларның кышкы уеннары. Әкияти геройлар.** | 23.12-28.12 | Татар халкының “Нардуган” бәйрәме турында төшенчә бирү, бәйрәм әзерләү, анда катнашу теләге уяту.Халкыбызның милли гореф-гадәтләренә һәм бәйрәмнәренә карата хөрмәт тәрбияләү.<br>Кышкы әкияти геройлар белән таныштыру.Тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү,балаларның игътибарын,хәтерен,фикерләрен,сүз байлыгын үстерү. | **Патриотик тәрбия** Иҗади хикәя төзү: «Кышкы уеннар» УМК 193 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе** Кул хезмәте: “Кыш бабай остаханәсе”<br>**Социаль тәрбия** Иҗади күзаллау уены «Карның файдасы һәм зыяны» УМК 56 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Дидактик уен «Парын тап» (бирелгән сүзләрне мәгънәләре буенча туры килерлек итеп парлаштыру). Мәсәлән: чаңгы – таяк УМК 193 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Хәрәкәтле уен «Чаналарга!УМК 188 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия** Матур әдәбият уку.<br>Лена Шагыйрьҗан **—**Ап-ак икән эзләрем” шигырен уку (Балачак аланы, 435 бит) |
| 18. | **Хуш киләсең, Яңа ел!** | 30.12-4.01 | Балаларда бәйрәмнәргә карата уңай мөнәсәбәт, үз фикереңне бер юнәлештә туплый һәм аны башкаларга җиткерә белү сыйфаты тәрбияләү, сөйләм телләрен, җырлау, бию сәләтләрен үстерүгә ярдәм итү. | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә. « Сорау җавап» уены» УМК 187 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе** “Иң пөхтә киенүче”<br>**Социаль тәрбия** .Дидактик уен «Дөрес тасвирла!»<br>**Танып белү тәрбиясе** Табышмак:УМК 194 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Җырлы-сүзле уен «Бу – Кыш бабай» УМК 195бит<br>**Этик-эстетик тәрбия** Иң кызыклы кулдан эшләгән битлек” конкурс |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 19. | **“Туган телем-татар теле” Әбиемнең серле сандыгы.** | 6.01-11.01 | Халык иҗаты аша телебезнең байлыгын, матурлыгын күрсәтү; Туган телебезне  ярату, зурлау, аңа соклану хисләре тәрбияләү.Балаларга үз ана телләрен тирәнтенрәк белергә, авазларны, сүзләрне дөрес әйтергә ярдәм итү. | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә. «Теле барның – иле бар» УМК 89 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе** Уен почмакларында тәртипне булдыру.<br>**Социаль тәрбия** Уен «Кулъяулык алыш» УМК 86 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Үстерешле уеннар: «Дөрес итеп милли киемнәрне тез!»<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** «Түбәтәйле» уены.УМК 183 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия**  Әбиләрнең кул эшләре күргәзмәсе. |
| 20. | **Ял итү өчен җәмәгать урыннары. Үз-үзеңне тәртиптә тоту кагыйдәләре. Театр, концерт залы, цирк һ.б.** | 13.01-18.01 | Театр, концерт залы, цирк һ.б. җәмәгать урыннары турында бала-ларның белемнәрен киңәйтү;<br>җәмәгать урыннарында үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре белән таныштыру;<br>башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышын күзәтү, чагыштыру, каршы кую, бәяли белү күнекмәләрен үстерү. | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә. «Паркта минем күргәннәрем» УМК 188 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе** Тирә-юньне кардан чистарту, баскыч төпләрен себерү.Урамнан кергәндә өсләрен, аякларын кагарга, бер- берсенә булышырга өйрәтү.<br>**Социаль тәрбия** Үстерешле уен «Фотога төшер!» (паркта күргән кызыклы вакыйгаларны күзаллап сөйләү).УМК 189 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Зиһен үстерешле уен «Уйла һәм әйт!»УМК 152<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Хәрәкәтле уен «Төлке һәм казлар» УМК 152 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия** “Курчак театрында Л. Шагыйрьҗан (Балачак аланы 501бит) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 21. | **Заманча әкиятләр.** | 20.01.-25.01 | Балаларда әкиятләр аша мәрхәмәтлелек, кыюлык, гаделлек, кунакчыллык, тыйнаклык сыйфатлары тәрбияләү. | **Патриотик тәрбия**<br>Әңгәмә:”Шагыйрь булу өчен нинди булырга кирәк”<br>**Хезмәт тәрбиясе**<br>Әкият персонажларына вак ремонт эшләре ясау.<br>**Социаль тәрбия**<br>“Өч аю” әкияте геройларына табын әзерләү.<br>**Танып белү тәрбиясе**<br>Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Кызыклы шәкерт».<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>“Сертотмас үрдәк”кә витаминнар җыелмасы (салат ясау)<br>**Этик-эстетик тәрбия**<br>Сәхнәләштерү: М.Җәлил. «Карак песи». |
| 22. | **Әти - әни һәм мин – сәламәт гаилә. Саулык- зур байлык. Спорт – сәламәтлек чыганагы.** | 27.01.-01.02 | Балаларда ихтыяр көче, сабырлык, кыюлык, җаваплылык, уен кагыйдәләрен үтәү сыйфатлары тәрбияләү.Спортның төрләренә карата кызыксынучанлык, мөстәкыйльлек үстерү. Балаларда үз сәламәтлекләренә карата игътибарлылык, сак караш тәрбияләү. | **Патриотик тәрбия**<br>Мәкаль: “Сәламәт тәндә – сәламәт акыл”<br>**Хезмәт тәрбиясе**<br>Уен өчен картоннан медальоннар эшләү.<br>**Социаль тәрбия**<br>Шигырь ятлау: Г.Юнысова. «Зарядкага бас» “Балачак аланы”. 307 бит<br>**Танып белү тәрбиясе**<br>Дидактик уен «Бу нинди спорт төре?»269 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>Уен:”Миңлебай”<br>**Этик-эстетик тәрбия**<br>Әңгәмә: “Чәчләрем матур булсын дисәң” (интернеттан алына) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 23. | **Мин кеше. Мин шәхес. Минем хокукларым.** | 03.02-08.02 | Балаларда әхлакый сыйфатлар, әти-әнигә хөрмәт тәрбияләү;балаларның гаиләдәге хокуклары турындагы белемнәрен ныгыту, аларның ялга, уенга хокуклы булуларын аңлату; | **Патриотик тәрбия**<br>Мультфильм карау: «Ике кыз» (Кайсы кызның нинди хокуклары бозылган?)<br>**Хезмәт тәрбиясе**<br>Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү. Төймәләрне каптыру.<br>**Социаль тәрбия**<br>Җыр тыңлау: «Дуслык җыры» (Ф.Сафин сүзләре, А.Гарифуллина көе).<br>**Танып белү тәрбиясе**<br>Исәнләшү (татарча – «исәнмесез!», башкортча – «һаумыһыгыз – дустар!», чувашча – «лайах!», удмуртча – «чырткемесь!», марича – «пеш сай юлташлак!»<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>Үзләре теләгән спорт уеннары<br>**Этик-эстетик тәрбия**<br>“Матур булу серләре” әңгәмә |
| 24. | **М. Җәлил – халык улы.** | 10.02-15.02 | М.Җәлил турында балаларның белемнәрен баету, аның әсәрләре белән танышуны дәвам итү;<br>герой-шагыйрьгә карата бәяләмә бирү, аның батырлыгына соклану хисләре тәрбияләү;<br>балаларда патриотик хисләр, Ватанны саклау теләге тәрбияләү. | **Патриотик тәрбия**<br>Мәкаль: «Халык әйтсә – хак әйтә» Батыр үзе үлсә дә, исеме үлмәс.<br>Эчтәлеге буенча фикер алышу<br>**Хезмәт тәрбиясе**<br>Муса Җәлилнең китабына вак ремонт эшләре<br>**Социаль тәрбия**<br>Шигырь уку: Р.Корбан. «Җәлил турында җыр».<br>**Танып белү тәрбиясе**<br>Сәхнәләштерү: М.Җәлил. “Карак песи”<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>**Этик-эстетик тәрбия**<br>“Карак песи” шигыренә рәсем ясау. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 25. | **Батырлыкта-матурлык.** | 17.02-22.02 | Балаларда кыю, батыр солдат булу теләге уяту; әтиләре, абыйлары белән горурлану хисе тәрбияләү;<br>Ватанны саклаучылар турындагы күзаллауларын киңәйтү; җирне, күкне, диңгезне саклаучылар турында белем бирү, аларның мөһимлеген аңлату; | **Патриотик тәрбия**<br>Сез ничек уйлыйсыз, хәрбиләр нинди булалар?<br>**Хезмәт тәрбиясе**<br>“Әтиләр көне”нә открытка ясау.<br>**Социаль тәрбия**<br>Проектордан солдатлар тормышын чагылдырган күренешләр күрсәтү.<br>**Танып белү тәрбиясе**<br>Дидактик уен «Таякчыклардан төзе» (танк, ракета, корабль, самолёт һ.б.)<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>“Матрослар” биюен өйрәнү<br>**Этик-эстетик тәрбия**<br>Җырлы-сүзле уен «Күрсәт әле, үскәнем» (солдатлар тормышы буенча) |
| 26. | **“Яз килә, яз килә, елмаеп кояш көлә!” Әниләр бәйрәме.** | 24.02-01.03 | Максатчыл күзәтү аша балаларны язгы табигать күренешләре белән таныштыру; соклану хисләре тәрбияләү; табигатьтәге бәйләнешләрне аңлата белү күнекмәлә-рен камилләштерү; рәсем буенча табигатьтәге үзгәрешләр турында сөйли белүләренә ирешү; | **Патриотик тәрбия** Рәсем буенча хикәя төзү. «Яз»<br>**Хезмәт тәрбиясе** Суган утырту, орлык чәчү<br>**Социаль тәрбия** «Яз килде» уены (рәсемнәр ярдәмендә). Балалар рәсемнәр буенча җөмләләр төзиләр һәм һәрбер җөмләгә хәрәкәтләр уйлап чыгаралар.<br>**Танып белү тәрбиясе** . Шигырь уку: М.Мазунов. «Яз килә»<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Сүзле, хәрәкәтле уен «Яз килә». УМК 248 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия** “ Иң оста ясалган сыерчык оясы” бәйгесе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 27. | **Сулар ага, бозлар китә, кошлар кайта җылы яклардан. Әниләр бәйрәме.** | 03.03-08.03 | Кошлар турында белемнәрен баету; тышкы билгеләренә карап кошларны танырга, исемнәрен әйтергә өйрәтү, кешеләрнең алар турында ничек кайгыртуын кузаллый белүне формалаштыру;<br>балаларның күзәтүчәнлекләрен, кызыксынучан-лыкларын, чагыштыра белү күнекмәләрен үстерү;су ташу, боз куркынычы турында аңлату. | **Патриотик тәрбия** Үстерешле уен. «Яз турында кем күбрәк сүз таба?» УМК 97 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе** Кул хезмәте:”Әниемә бүләк”<br>**Социаль тәрбия** Дидактик уен. «Сорау – җавап».УМК 252 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Дидактик уен «Кемнең әнисе кайда эшли?» УМК 94 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Сүзле-хәрәкәтле уен «Күрсәт әле, үскәнем».<br>**Этик-эстетик тәрбия** “Әнием кадерлем” балалар белән әниләр бәйрәмен үткәрү. |
| 28. | **Су - яшәү чыганагы. Җир көне.** | 10.03-15.03 | Балаларның су, аның үзенчәлекләре, табигатьтә була торган үзгәрешләр турында белемнәрен киңәйтү;<br>яңгырның каян килеп чыгуын аңлату; гади тәҗрибәләр һәм уеннар аша балаларның су үзенчәлекләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>яшәү чыганагы булган суга,җиргә сак караш тәрбияләү;<br>табигатькә соклана һәм аның гүзәллеген күрә белергә өйрәтү. | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә: Су - яшәү чыганагы. Җир көне.<br>**Хезмәт тәрбиясе** Тәҗрибә. «Суның үзенчәлекләре УМК 110 бит<br>**Социаль тәрбия** Әңгәмә: «Яңгыр ничек барлыкка килә?»<br>**Танып белү тәрбиясе** Зиһен үстерешле уен «Яңгырның файдасы һәм зыяны» УМК 109 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Хәрәкәтле уен «Яр – су» УМК 111 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия** Яшәү чыганагы –ул СУ!” Гаилә белән рәсем бәйгесе. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 29. | **Куркынычсызлык. Уттан саклан!** | 17.03-22.03 | Балаларны өйдә , урамда, ял итү урыннарында булырга мөмкин куркынычлар белән таныштыру;гади генә куркынычсылык кагыйдәләре белән таныштыру, аларны куллана белергә өйрәтү;янгынның нинди куркыныч күренеш булуын , янгын чыккан очракта ни эшләргә икәнен аңлату. | **Патриотик тәрбия**<br>«Янгын бүлегендә мин нәрсә күрдем?» Балаларның үз рәсемнәре буенча фикерләрен тыңлау. Янгын сүндерүчеләр нинди булырга тиеш?<br>**Хезмәт тәрбиясе**<br>Янгын куркынычсызлыгы почмагындагы машиналарга, уеннарга вак ремонт эшләре үткәрү.<br>**Социаль тәрбия**<br>Үстерешле уен «Кагыйдәне бел!» - Шырпы белән уйнама! - Электр әйберләренә зурлардан башка кагылма!һ.б.<br>**Танып белү тәрбиясе**<br>«Булсаң зирәк – әйт тизрәк!» уены. - Нәрсә ул янгын? - Ут кешеләргә нинди зыян (файда) китерә?<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>Хәрәкәтле уен «Яр – су».”Туган телдә сөйләшәбез” 111 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия**<br>Рәсем ясау “Янгын сүндерү машинасы” |
| 30. | **“Юлда йөрсәң бул өлгер, юл кагыйдәсен нык бел!” Юл йөрү кагыйдәләре, билгеләре.** | 24.03.-29.03 | Балаларның юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен камилләштерү. Юлда, җәмәгать транспортында үз-үзеңне тоту күнекмәләре тәрбияләү. | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә: «Велосипед – минем дустым».УМК 80 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе** регулировщик хезмәте белән таныштыру. С/рольле уен “Регулировщик»<br>**Социаль тәрбия** Дидактик уен «Юл билгесен дөрес куй!»<br>**Танып белү тәрбиясе** Үстерешле диалог.УМК 79 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Уен «Светофор»81 бит.<br>**Этик-эстетик тәрбия**“Минем яраткан машинам”рәсем күргәзмәсе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 31. | **Урман-жиребезнең матурлыгы, байлыгы** | 31.03-05.04 | Балаларны безнең якның урманнары, анда үсә торган агачлар, чәчәкләр, яши торган җәнлекләр, кошлар белән таныштыру;урманның файдасы никадәр күп икәнен аңлату. | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә. «Урман – безнең байлыгыбыз» УМК 256<br>**Хезмәт тәрбиясе** куак, агач төпләрен йомшарту.<br>**Социаль тәрбия** Үстерешле уен «Урман кагыйдәләре» (туп белән). УМК 255<br>**Танып белү тәрбиясе** Дидактик уен «Табышмак буенча агачны бел һәм күрсәт» УМК 123<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Сүзле-хәрәкәтле уен «Урманда» УМК 255<br>**Этик-эстетик тәрбия** "Урман аланында" кисеп-ябыштыру конкурсы. |
| 32. | **Галәм киңлекләре.** | 07.04-12.04 | Балаларда беренче очучы Ю.Гагарин белән танышу аша илебезгә карата горурлык хисләре тәрбияләү;<br>Галәм турындагы белемнәрен системалаштыру;<br>Кояш системасы, планета-лар турында элементар белешмә бирү, алар ту-рында күбрәк беләсе килү теләге уяту; | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә. «Космонавтика көне» УМК 264<br>**Хезмәт тәрбиясе** Кул хезмәте: "Йолдызлар кисү"<br>**Социаль тәрбия** Космик табышмаклар УМК 267<br>**Танып белү тәрбиясе** Уен-викторина (туп белән) УМК 265<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе.** Сүзле уен «Кояш һәм йолдызлар». [з] авазы (сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр башкарыла) УМК 264<br>**Этик-эстетик тәрбия** Космоска юл- рәсем |
| 33. | **Хезмәт төбе-хәзинә.** | 14.04-19.04 | Балаларның өлкәннәр хезмәте, аларның һөнәрләре турында белемнәрен киңәйтү, алар хезмәтенең мөһимлеген аңлату;<br>балаларда һөнәр осталарының матур эшләренә соклану, аларның хезмәтенә хөрмәт, горурлык хисләре тәрбияләү. | **Патриотик тәрбия Тема.** Әңгәмә. «Кем булырга?» УМК 83 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе** "Әниләребезнең һөнәрләре" (өлкәннәр хезмәте белән таныштыру)<br>**Социаль тәрбия** Дидактик уен «Парын тап».УМК 84 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Бармак уены «Һөнәрләр». УМК 84 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Җырлы уен. «Кәрия-Зәкәрия» көенә. УМК 84 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия** "Әти, әни һәм мин" фотокүргәзмә. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 34. | **Г.Тукай - безнең күңелләрдә** | 21.04-26.04 | Г.Тукайның тормыш һәм иҗат юлы белән таныш-тыру; балаларда Г.Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту,таныш әдәби сюжетлар буенча бала-ларның Г.Тукай иҗаты буенча алган белемнәрен камилләштерү;<br>шагыйрьгә,шагыйрьнең иҗатына карата мәхәббәт, ихтирам хисләре тәрбияләү;<br>Г.Тукай әкиятләре, шигырьләре аша балалар да матур әдәбият белән кызыксыну, аларны укырга теләк тәрбияләү, тырышлык, игътибарлылык, сабырлык кебек сыйфатлар тәрбияләү. | **Патриотик тәрбия**<br>Конкурс «Нәни тел остасы» (балалар әти-әниләре белән берлектә ятлаган шигырьләрне яттан сөйлиләр).<br>**Хезмәт тәрбиясе**<br>Г.Тукай әкиятләрен сәхнәләштерү өчен кирәк – яраклар әзерләү.<br>**Социаль тәрбия**<br>Мультфильм карау: «Кәҗә белән сарык».<br>**Танып белү тәрбиясе**<br>Дидактик уен «Табышмакның җавабын әйт – кайсы әсәрдән икәнен бел!»<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе**<br>Хәрәкәтле уеннар: “Балык тоту”, Төлке һәм казлар”, “Буяулы”<br>Бурычлар: Балаларның хәрәкәт итү күнекмәләрен, җитезлекләрен үстерү.<br>**Этик-эстетик тәрбия**<br>Г.Тукайның “Туган тел” җырын өйрәнү.<br>Бурыч:Телнең сәнгатьлелеген камилләштерү, хәтер сәләтен үстерү. |
| 35. | **Язучыларыбыз иҗаты.** | 28.04-03.05 | Татар шагыйрьләре белән танышуны дәвам итү,балаларның уй-фикерләү сәләтен, хәтерләрен үстерү;балаларда язучыларыбыз иҗатына карата кызыксыну уяту, ихтирам тәрбияләү. Сугышчыларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында балаларның белемнәрен арттыру;<br>Бөек Ватан сугышы геройлары , аларның күрсәткән батырлыклары турында күзаллауларын киңәйтү;<br>Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкларын үстерү;<br>. | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә. “Яраткан әкиятләребез”. Әкиятләрне искә төшерү.<br>**Хезмәт тәрбиясе** Тирә-юньне җыештыру.<br>**Социаль тәрбия** Үстерешле уен «Бу кайсы әкият герое?» (А.Алиш әкиятләре буенча УМК 151 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Зиһен үстерешле уен «Уйла һәм әйт!» УМК 152 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** «Үрдәккә туры китер!» уены.УМК 154<br>**Этик-эстетик тәрбия** Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Бала белән күбәләк» УМК 120 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 36. | **Җиңү алып килгән яз.** | 05.05-10.05 | Сугышчыларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында балаларның белемнәрен арттыру;<br>Бөек Ватан сугышы геройлары , аларның күрсәткән батырлыклары турында күзаллауларын киңәйтү;<br>Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкларын үстерү; | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә. Балаларга Бөек Ватан сугышы турында мәгълүмат бирү, хәтер китабы белән танышу. УМК 278<br>**Хезмәт тәрбиясе** Кул хезмәте - “Җиңү бәйрәменә открытка”<br>**Социаль тәрбия** С/р.у «Хәрби гараж».<br>**Танып белү тәрбиясе** «Хәтер» китабы белән танышу. УМК 278 бит<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Хәрәкәтле уен «Кем җитез?»УМК 279 б.<br>**Этик-эстетик тәрбия** Митингта катнашу<br>“Без тынычлык телибез!” – балалар рәсеменнән күргәзмә. |
| 37. | **Мониторинг Тиздән- җәй!** | 12.05-17.05 | Җәй турында күзаллауны киңәйтү, белемнәрен ныгыту;табигатькә аңлы караш, экологик культура тәрбияләү;<br>Балаларның белем, фикерләү дәрәҗәләрен тикшерү;<br>мәктәп турында мәгълүмат бирү, аларда белем алуга омтылыш уяту | **Патриотик тәрбия** Әңгәмә. “Язгы үзгәрешләр”<br>**Хезмәт тәрбиясе** Бакча территориясен матурлауда ярдәм итү, чәчәкләр утырту<br>**Социаль тәрбия** Өстәл уены.“Рәсемдә ниләр бар?”<br>**Танып белү тәрбиясе** Табышмаклар.<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Уен. “Куып тот!”<br>**Этик-эстетик тәрбия** Матур әдәбият.<br>Ф.Зариф “Чишмә”<br>Балачак аланы, 245 бит |
| 38 | **Бүлмә гөлләре. Чәчәкләр-тормыш яме. (мәктәпкә хәзерлек төркеме : “Сау бул, бакча!!!”)** | 19.05-24.05.<br><br>26.05-31.05 | Гөлләр, чәчәкләрне танырга өйрәтү; Матурлыкка соклана белергә, аны булдыру өчен тырышлык кирәк икәненә төшендерү. Балаларда үсемлекләргә карата сак караш, шәфкатьлелек, миһербанлылык тәрбияләү, матур әдәбият аша эстетик тойгылар уяту. | **Патриотик тәрбия** Фикер алышу 130 бит<br>**Хезмәт тәрбиясе** Гөлләр күчереп утырту.<br>**Социаль тәрбия** Уен-викторина «Мин кайда үсәм?» УМК 130 бит<br>**Танып белү тәрбиясе** Уен:“Кайсы артык?”<br>**Физик һәм сәламәтлек тәрбиясе** Җырлы уен «Түгәрәк алан».УМК 131 бит<br>**Этик-эстетик тәрбия “**Өзмик матур гөлләрне”-рәсем күргәзмәсе |